**МИНИСТЕРСТВО**
**ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ**
**МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**09.04.2019** **№94**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә яллаучы як вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки идарәнең коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт итә торган Тәртипләрне раслау турында

2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында» дип исемләнгән 17нче Федераль законның 1нче маддә 3нче пункты нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә яллаучы як вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки идарәнең коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт итә торган Тәртипләрне расларга.

2. Яшьләр эшләре министрлыгының (моннан соң – министрлык) эш башкару һәм контрольдә тоту секторына Министрлыктагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендәге затларны, боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәлгәннән соң, әлеге боерык белән таныштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны Министрлыкның эшләр белән идарә итүче Э.М.Әхмәтгәрәевка йөкләргә.

**Министр** **Д.И.Фәттахов**

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрлыгы
боерыгы нигезендә
09.04.2019 елда 94нче номер сугып
расланды

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә яллаучы як вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки идарәнең коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт итә торган Тәртип

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә яллаучы як вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки идарәнең коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт итә торган Тәртип (моннан соң − Тәртип) 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында» дип исемләнгән 17 нче Федераль законның 1 нче маддә 3 нче пункты нигезендә эшләнгән..

Бу тәртиб Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә яллаучы якның вәкиле тарафыннан бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында (алга таба - гражданлык хезмәткәрләре, Министрлык) түләүсез нигездә иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, күчемсез милекчеләр ширкәте (алга таба - коммерцияле булмаган оешма) белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү процедурасын регламентлый.

Бу тәртип Министрлыктагы Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтендәге затларга (аларны яллаучы як буларак Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министры булган хәлдә (моннан соң – министр) кагыла.

2. Бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү турында гариза (алга таба - Гариза)

гражданлык хезмәткәре тарафыннан язма формада бу Тәртипкә беркетелгән 1нче Кушымта буенча төзелә.

3. Гражданлык хезмәткәре Гаризаны коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча җаваплы затка (алга таба – Җаваплы зат) тапшыра.

4. Җаваплы зат Гаризаны алынган көнне бу Тәртипкә беркетелгән 2нче Кушымта нигезендә Журналда терки.

5. Җаваплы зат Гаризаны алдан карап, аның нәтиҗәләре буенча йомгак ясый.

Җаваплы зат Гаризаны алдан караган очракта, Гариза биргән гражданлык хезмәткәреннән коммерцияле булмаган оешма идарәсендә планлаштырылган катнашу буенча вазифаларын билгели торган язма аңлатма һәм документлар соратып алырга хокуклы.

Нәтиҗәдә гражданлык хезмәткәренә түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү яки рөхсәт бирмәү турында тәкъдим булырга тиеш.

6. Гариза теркәлгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча җаваплы зат Нәтиҗә һәм башка материалларны (булган очракта) Гаризага беркетеп, гражданлык хезмәткәренә түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү яки рөхсәт бирмәү турында карар кабул итү өчен, министрга (аның вазифаларын башкаручыга) тапшыра.

Министр (аның вазифаларын башкаручы) Гариза алынганнан соң ике эш көне дәвамында карар кабул итә.

7. Министр (аның вазифаларын башкаручысы) карар кабул иткәннән соң ике эш көне дәвамында, Җаваплы зат гражданлык хезмәткәренә Гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа кул куйдырып, дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик хезмәт секторы мөһере сугылган, министр резолюциясе булган Гариза күчермәсен тапшыра. Гаризаның министр резолюциясе булган төп нөсхәсе гражданлык хезмәткәренең шәхси эшенә беркетелә.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә яллаучы як вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки идарәнең коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт итә торган Тәртибенә беркетелгән 1нче номерлы Кушымта

______________________________
(Ф.И.О.)
____________________________
(ФИО., вазифа һәм структуралы
________________________________
___
бүлекчә, тору урыны адресы
________________________________
телефон номеры)

Гариза

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә яллаучы як вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки идарәнең коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү турында

Миңа идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә (кирәклесе астына сызарга) рөхсәт бирүегезне сорыйм ______________________________________________________________________________ _____________
(иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, ______________________________________________________________________________ _____________, күчемсез милекчеләр ширкәте исеме)

түләүсез нигездә

______________________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________________

_______________

(бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган яки коллегиаль идарә органы исеме)

_____________ ____________________ ________________________________

(дата) (имза) (фамилия, инициаллар)

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә яллаучы як вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки идарәнең коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт итә торган Тәртибенә беркетелгән 2нче номерлы Кушымта

Журнал

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә яллаучы як вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки идарәнең коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт итә торган гаризаларны теркәү ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Дата | Ходатайство бирүченең ФИО, вазифасы | Ходатайство бирүченең имзасы | Теркәүченең ФИОсы | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |